**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

**тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 1-26** **« 17 » сентябрь 2018 ел**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 нче елның 18 нче октябрендә кабул ителгән 1-26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының 2014 елның 18 нче октябрендә кабул ителгән 1-26 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын (үзара салым акчаларын җыю тәртибе) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.«Үзара салым акчаларын җыю тәртибе Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башкарма комитетыны хокукый акты белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башлыгы А.П.Ивановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре башлыгы,
шәһәр Советы рәисе А.П. Иванов